Республика Татарстан
Глава
Вахитовского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге
башлыгы

ул.Центральная, д. 30, пос.Победа
Азнакаевский район, 423312

Үзәк урамы, 29 нче йорт, Җиңү
бистәсе, Азнакай районы, 423312

Тел. (факс) 8(85592) 42-1-38; e-mail: Vahit.Azn@tatar.ru
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» апрель 2021 ел № 2

Азнакай муниципаль районы
«Вахитов авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә
җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару
кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча
ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 31 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль берәмлеге «Вахитов авыл җирлеге» Уставы, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советының 17.02.2014 № 86 карары белән расланган (2016 елның 16 декабрендәге 46 номерлы, 2017 елның 14 июлендәге 63 номерлы, 2018 елның 26 мартындагы 125 номерлы , 2020 елның 18 февралендәге 154 номерлы карарлар редакциясендә) Азнакай муниципаль районы "Вахитов авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

1.1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында

- Заречье бистәсе, Үзәк урам , 20 нче йорт адресы буенча урнашкан 16:02:170102:48 кадастр номеры булган ОД1 зонасы өчен территориаль зонаны шәхси төзелеш Ж1 зонасына үзгәртергә.

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш эшләре проектын әзерләү буенча халык алдында тыңлауларны оештыручы комиссияне;

- үткәрү вакыты - 2021 елның 29 апрелендә 15.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрү урыны – Победа авылы, Узәк урам, 29 йорт;

- фикер алышына торган мәсьәлә буенча 2021 елның 29 апреленә кадәр язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә ала торган адрес: Победа авылы, Узәк урам, 29 йорт, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге башкарма комитеты.

4. Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш эшләре проектын әзерләү буенча комиссиягә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Вахитов выл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда үзгәрешләр кертү турында проект буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

- ачык тыңлауларны үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Вахитов авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проектны Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча : http://aznakaevo.tatar.ru//, 2021 елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http/ / aznakayevo.tatar.ru// урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык ____________ И.Б.Бохарова